Рон

# Гаилә һәм мәктәп

12+
11 (52)
ноябрь 2017



КОЛАКТА – НАУШНИК
КУЛДА – СПИННЕР...

«МИН ХӘЕРЧЕ
БУЛАММЫ?»

ХАТЛАРГА
САЛЫНГАН МӘХӘББӘТ

# КӨЗГЕ ЯФРАКЛАРДАН ШАР

**Кирәкле әйберләр:**

- пенопласт шар
- агач таякчыклар
- төрле яфрак калыплары
- төсле картон
- кайчы
- гади карандаш
- термоҗилем


**Эш барышы:**

1. Пенопласттан ясалган шарга агач таякчыкларны беркетеп чыгабыз. Төшеп китмәсеннәр өчен термоҗилем белән ныгытабыз.
2. Таякчыкларның аралары якынрак булган саен, шар шулкадәр матуррак килеп чыгачак.
3. Кирәк кадәрле санда яфраклар кисәбез.
4. Һәр яфракны урта бер өлешеннән җилем ярдәмендә таякчыкка беркетәбез.
5. Бер таякчыкка җеп бәйлибез һәм түшәмгә яки ишек башына элеп куябыз.













**Светлана ГАТИНА,**
Алексеевск районы
Балалар иҗаты үзәгенең
өстәмә белем бирү буенча педагогы.

Ел фасылына карап, чәчәкле, кар бөртекле шар ясарга була. Әз генә җилдән дә әйләнеп торган әлеге шарчык күңелгә рәхәтлек бирә.

## Дустың булса, шундый булсын!



Дуслар нинди була дисезме? Әлбәттә, бер-берсенә карата ярдәмчел, игътибарлы була алар. Без дә Яңа ел якынлашканын сизеп, безгә тугры булган укучыларыбыз арасында көндәлек тормышта кирәк булган техника – чәйнек, миксер, блендер уйнатырга булдык.

Бүләк уйнатуда катнашу шартлары бик гади. Бары тик 2018 елның беренче яртыеллыгына безнең журналга язылаcы һәм квитанция күчермәсен: 420066 Казан, Декабристлар урамы, 2 йорт адресы буенча яки gaila-mektep@mail.ru электрон почтасы аша редакциягә юллыйсы гына бар. Конверт тышына «Яңа елга бүләк белән» дип тә язарга, элемтә өчен телефон номерыгызны күрсәтергә онытмагыз.

Хатлар 12 гыйнварга кадәр кабул ителә. Ә 15 гыйнварда без уңыш елмайган дусларыбызның исемен Инстаграмм челтәрендәге сәхифәбез аша туры эфирда беләчәкбез.

Катнашырга ашыгыгыз, дуслар! Бәлки нәкъ менә сезгә уңыш елмаер!